**КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ**

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2016 ел, 8 февраль № 79

г. Казань

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарлары үз көчен югалтуын тану турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының түбәндәге карарлары үз көчен югалткан дип танырга:

«Медицина күрсәткечләре булганда шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү, шулай ук шәһәрара транспортта дәвалану урынына түләүсез бару һәм кире кайту өлешендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләрен раслау турында» 2011 ел, 29 июнь, 528 нче;

«Инвалидларга һәм ветераннар арасындагы гражданнарның аерым категорияләренә социаль яклау чараларын күрсәтү турында, шулай ук шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү һәм шәһәрара транспортта түләүсез дәвалану урынына бару һәм аннан кире кайту рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү хакында» 2011 ел, 20 октябрь, 877 нче;

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2011 ел, 29 июнь, 528 нче карары белән раслаган Медицина күрсәткечләре булганда шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү, шулай ук шәһәрара транспортта дәвалану урынына түләүсез бару һәм кире кайту өлешендә гражданнарның аерым категорияләренә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субвенцияләрне тоту кагыйдәләренә үзгәреш кертү турында» 2013 ел, 2 октябрь, 712 нче;

«Инвалидларга һәм ветераннар арасындагы гражданнарның аерым категорияләренә социаль яклау чараларын күрсәтү турында, шулай ук шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү һәм шәһәрара транспортта түләүсез дәвалану урынына бару һәм аннан кире кайту рәвешендә

дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү хакында» 2011 ел, 20 октябрь, 877 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 27 гыйнвар, 43 нче;

«Инвалидларга һәм ветераннар арасындагы гражданнарның аерым категорияләренә социаль яклау чараларын күрсәтү турында, шулай ук шифаханә-курорт дәвалавына юлламалар бирү буенча социаль хезмәтләр күрсәтү һәм шәһәрара транспортта түләүсез дәвалану урынына бару һәм аннан кире кайту рәвешендә дәүләт социаль ярдәмен күрсәтү хакында» 2011 ел, 20 октябрь, 877 нче карарына үзгәрешләр кертү турында» 2014 ел, 25 июль, 545 нче.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры И.Ш.Халиков

F:\KARAR\2016\79.docx